СОВЕТ КИЛЬДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КИЛДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

14.12.2017 с. Кильдеево 33-161

Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары турында

Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге башкарма комитетының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасы һәм 29.4 статьясы нигезендә эшләнгән Килди авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары турында мәгълүматын тыңлаганнан соң, Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге халкының тормыш-көнкүрешен уңай шартлар белән тәэмин итүгә һәм җирле әһәмияттәге объектлар белән тәэмин ителешнең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсен һәм мондый объектларның территориаль яктан мөмкин булган максималь дәрәҗәдә үтемле булуын исәпләү күрсәткечләрен билгеләүгә юнәлдерелгән озак сроклы шәһәр төзелеше сәясәтен булдыру максатларында;

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Советы
карар итте

1. Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеген шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Килди авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Советының җир мәсьәләләре, төзекләндерү һәм табигать ресурслары буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районының
Килди авыл җирлеге башлыгы В. М. Бурдин